Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Уракчы авыл җирлеге составына керүче
Мельничный Починок авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

01 апрель 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 01 апрелендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: "Сез гражданнар Җыененың 18.10.2023 ел 2 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә ризамы:

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган үзара салым акчалары юнәлтелгән эш төрләре исемлегеннән түбәндәге пунктларны алып атырга:

-торак пунктлар чикләрендә урамнарны яктырту челтәрләрен тоту (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам утларын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү;

- авыл җирлеге чикләрендә су белән тәэмин итү системасын тәртиптә тоту (суэтем башняларына тирәнлек насослары сатып алу өчен);

- торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау;

-авыл җирлеге чикләрендә кышкы юлларны карап тоту (кышкы чорда юлларны кардан чистарту-килешү буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

- авыл җирлеге территориясен җәй көне чабу (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу , килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

-Уракчы авылы Мәдәният йорты яны территориясен төзекләндерү (янәшәдәге территориянең коймаларын алыштыру, Мәдәният йорты бинасының фасадын буяу).

2. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган үзара салым акчалары юнәлтелгән эш төрләре исемлегенә түбәндәге пунктларны кертергә:

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

- су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны тәэмин итә торган башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;
-торак пункт территориясен төзекләндерү.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Урахча авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Уракчы авылы, Совет урамы, 36Айорт; Мельничный Починок авылы, Киров урамы, 20Б йорты Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Уракчы авыл җирлеге Башлыгы: Ф.М.Гәрәев